**<u>Медицина хезмәте күрсәтү турында</u>**

**Сәламәтлекне саклауга һәм медицина ярдәменә хокук**

*<u>Сәламәтлек – кешенең физик, психик һәм социаль торыштагы авырулары булмаган, шулай ук органнарында һәм организм системаларында берниндi дә җитешсезлекләр булмаган иминлеге.</u>*
Бу билгеләмә «Россия Федерациясендә гражданнарның сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән. Моннан тыш, Россия Федерациясе Конституциясенең 41 статьясының беренче өлеше нигезендә *һәр кеше сәламәтлеген саклауга һәм медицина ярдәменә хокуклы.*
*<u>Сәламәтлекне саклауның төп принциплары</u>* булып тора:
1) сәламәтлекне саклау өлкәсендә гражданнарның хокукларын саклау һәм әлеге хокуклар белән бәйле дәүләт гарантияләрен тәэмин итү;
2) медицина ярдәмен күрсәткәндә пациентлар мәнфәгате өстенлеге;
3) балалар сәламәтлеген саклауның өстенлеге;
4) сәламәтлекләрен югалту очрагында гражданнарның социаль якланганлыгы;
5) дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының, гражданнарның сәламәтлек саклау өлкәсендәге хокукларын тәэмин итүче оешмаларның урындагы затларының җаваплылыгы;
6) медицина ярдәмен алуның бар кешегә дә уңайлы булуы һәм сыйфаты;
7) медицина ярдәме күрсәтүдән баш тартуга юл куелмау;
8) сәламәтлек саклау өлкәсендә профилактика өстенлеге;
9) табиб серен саклау.
*<u>Һәр гражданин үз сәламәтлеге турында үзе аңлаган формада түбәндәгеләрне эченә алган мәгълүматны белергә хокуклы:</u>*
*тикшерү нәтиҗәләрен*;
*авыруы бармы-юкмы икәнлеген, диагнозын һәм прогнозны*;
*дәвалау төрләрен һәм алар белән бәйле рискларны*;
*медицина тәэсир итүләренең, аларның нәтиҗәләренең һәм уздырылган дәвалау нәтиҗәләренең мөмкин булган вариантларын.*

**Пациентның хокуклары**

*<u>Пациент</u> – медицина ярдәме күрсәтелә торган яки авыруы булу яки булмауга һәм хәленең торышыннан бәйсез рәвештә медицина ярдәме күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән зат.*
*<u>Һәр пациент хокуклы:</u>*

- табибны һәм медицина оешмасын сайлауга;
- профилактикага, диагностикага, дәвалануга, санитар-гигиеник таләпләргә җавап бирә торган медицина оешмаларында медицина реабилитациясенә;
- табиб-белгечләр консультациясен алуга;
- авыру һәм (яки) медицина тәэсир итүе белән бәйле авыртуны мөмкин булган алымнар һәм дарулар белән җиңеләйтүгә;
- үз хокуклары һәм бурычлары, үз сәламәтлеге торышы турындагы мәгълүматны алуга;
- пациент мәнфәгатьләрендә аның сәламәтлеге турындагы мәгълүматларны белеп торырга тиешле затларны сайлауга;
- стационар шартларда дәвалану алган чакта туклануга;
- табиб серен тәшкил иткән мәгълүматларның саклануына;
- медицина тәэсир итүләреннән баш тартырга;
- медицина ярдәме күрсәтелгән чакта китерелгән зыянның каплануына;
- аның хокукларын яклау өчен аның янына адвокатның яки законлы вәкилнең кертелүенә; аның янына дин белгече кертелүгә, пациент стационар шартларда дәваланган очракта - дини йолаларны башкару өчен шартлар тудырылуга, шул исәптән, әгәр дә бу хастаханәнең эчке таләпләренә каршы килми икән, әлеге максатлар өчен аерым бүлмә бирелүгә.

**Пациентның хокуклары бозылганда кая мөрәҗәгать итәргә?**

Пациент турыдан-туры аңа медицина ярдәме күрсәтелә торган <u>*медицина оешмасы җитәкчесенә яки оешманың башка урындагы затына, тиешле профессиональ медицина ассоциацияләренә яки судка*</u> мөрәҗәгать итә ала.
Пациентка китерелгән зыян өчен медицина оешмасы җаваплы.
Җаваплылык түбәндәге очракларда туа:
<u>*хокукка каршы килү*</u> (законнар һәм башка норматив хокукый актлар таләпләренә каршы килү); <u>*медицина оешмасы (аның персоналының) гамәлләре (гамәл кылмавы); пациентка зыян китерү; хокукка каршы килү гамәленең зыян китерү белән бәйле булуы;*</u> медицина оешмасы <u>*гаебе була.*</u>